Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Советының егерме тугызынчы утырышы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы
карары

5 декабрь, 2019 ел №237

Демографик хәл, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы халкына медицина хезмәте күрсәтүне камилләштерү чаралары турында

Демографик хәл, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы халкына медицина хезмәте күрсәтүне камилләштерү турында мәгълүматны тыңлаганнан соң, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Демографик хәл, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы халкына медицина хезмәте күрсәтүне камилләштерү буенча чаралар турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетына «Питрәч РҮХ» ДАССО белән берлектә тәкъдим итәргә:

- «Демография һәм «Сәламәтлек саклау» милли проектлары буенча төп күрсәткечләргә ирешүгә анализ ясарга, проблемаларны, аларны хәл итү юлларын билгеләргә;
- район халкының репродуктив сәламәтлеген саклау буенча эшне көчәйтергә;
- сәламәтлек саклауның беренчел звеносына (фельдшер-акушерлык пунктларына) медицина кадрлары белән тәэмин итү буенча чаралар күрергә;
- гаилә институтын, гаилә кыйммәтләрен ныгыту, җәмгыятьтә гаилә һәм аналык ролен арттыру буенча эшне тормышка ашыру.

3. Әлеге карарны Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Советының социаль мәсьәләләр, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният һәм яшьләр эшләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И. М. Кашапов